# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 7 июлендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә дәүләт тикшереп торуын һәм күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында" 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучылар акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлекнең төзүче тарафыннан гамәлгә ашырылуын билгеле бер срокка туктатып тору турындагы гариза белән йә Федераль законда билгеләнгән очракларда төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затны ликвидацияләү турындагы гариза белән арбитраж судка мөрәҗәгать итү;";

б) түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

"рәсми статистик мәгълүмат булдыру вазыйфаларын гамәлгә ашырырга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен төзүчеләрнең өлешле төзүдә катнашучылар акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

күчемсез мөлкәтне дәүләт кадастры исәбенә алуны гамәлгә ашырырга һәм күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастрын алып барырга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органыннан, шулай ук күчемсез мөлкәткә һәм алар белән алыш-биреш килешүләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнардан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен төзүчеләрнең өлешле төзүдә катнашучылар акчаларын җәлеп итүгә бәйле эшчәнлеген тикшереп тору өчен кирәкле документлар һәм мәгълүмат алу;

төзелеш өчен гражданнарның акчаларын җәлеп итүне гамәлгә ашыручы затлардан дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле һәм исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә торган белешмәләрне һәм (яисә) документларны җирле үзидарә органының тиешле гарызнамәсен алган көннән соң 10 көн эчендә алу.";

2) 6 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $5^1$ пункт өстәргә:

"$5^1$) әлеге Законның 1 статьясындагы тугызынчы абзацында каралган гаризалар белән арбитраж судка мөрәҗәгать иткән очракта, төзүчене ликвидацияләү яисә төзүче тарафыннан күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын төзү (булдыру) өчен өлешле төзүдә катнашучылар акчаларын җәлеп итү белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыруны туктатып тору турындагы арбитраж суд карары үз көченә кергән көннән соң биш эш көне эчендә күчемсез мөлкәткә һәм алар белән алыш-биреш килешүләренә хокукларны дәүләт теркәвенә алучы органнарга судның тиешле карары үз көченә керү турында хәбәр итәргә;";

3) 8 статьяда "хисап кварталыннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр" сүзләрен "хисап кварталы тәмамланганнан соң 45 көннән дә соңга калмыйча, хисап чорыннан соң килә торган елның 1 апреленнән дә соңга калмыйча бирелә торган дүртенче квартал хисаплылыгыннан гайре," сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 1 августы
№ 43-ТРЗ